| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**16.09.2021** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 2269** |

2021 елның III кварталына гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең максималь күләмен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, 2007 елның 13 июлендәге «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак - коммуналь хуҗалык министрлыгының «2021 елның икенче яртыеллыгына Россия Федерациясе буенча торак урынының бер квадрат метр гомуми мәйданының нормативы һәм 2021 елның III кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткечләре турында» 07.06.2021 ел, №358/пр боерыгы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип тану турында карар кабул итү өчен 2021 елның III кварталына гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең максималь күләмен түбәндәгечә билгеләргә:

1.1. Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләме:

1.1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен-20 368,47 сум;

1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 20 368,47 сум;

1.1.3. өч кешедән торган гаилә өчен – 20 368,47 сум.

1.2. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме:

1.2.1. ялгыз яшәүче граждан өчен-1 055 772 сум;

1.2.2. ике кешедән торган гаилә өчен - 2 111 544 сум;

1.2.3. өч кешедән торган гаилә өчен-3 167 316 сум;

1.2.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен-4 223 088 сум;

1.2.5. биш кешедән торган гаилә өчен – 5 278 860 сум;

1.2.6. алты кешедән торган гаилә өчен – 6 334 632 сум;

1.2.7. җиде кешедән торган гаилә өчен – 7 390 404 сум.

2. Гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип таныганда, «Зеленодольск муниципаль районының торак сәясәте департаменты» МКУ муниципаль торак фонды бүлегенә әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктларында күрсәтелгән күрсәткечләрне кулланырга.

3. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында һәм Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында(http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru)бастырып чыгарырга .

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И. Р. Ганиев